**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11683**
**01.12.2023**

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4419 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4419 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 1 августындагы 3860 номерлы, 2023 елның 31 августындагы 7913 номерлы карарлары редакциясендә) расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – административ регламент), 2.9.3 пунктка «күчемсез мөлкәт өчен һәм өч елдан ким – күчемле мөлкәт өчен.» сүзләрен өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов